**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЗЕЛЕНОДОЛЬСК муниципаль районы**
**КАРАМАЛЫ ТАУ ШӘҺӘР ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР

2019 елның 3 июне №182

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегендә Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренең шәһәр төзелешен зоналаштыру картасына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 31-33 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге уставына таянып, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы» «муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегенең 2019 елның 29 маендагы гавами тыңлаулар үткәрү турындагы беркетмәсе һәм бәяләмәсе нигезендә Карамалы Тау шәһәр җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренең шәһәр төзелешен зоналаштыру картасына түбәндәге кадастр номерлары булган җир кишәрлекләре территориаль зонасын үзгәртү өлешендә үзгәрешләр кертергә:

- 16:20:020118:121, 16:20:020118:122, түбәндәге адрес буенча урнашкан: Татарстан Республикасы, Зеленодольск муниципаль районы, Карамалы Тау штп Кузнечная урамы Ж-1дан (индивидуаль торак йортлар төзү зонасы) КО-1 га (коммуналь объектлар зонасы );
- 16:20:020116:138, 16:20:020116:139, түбәндәге адрес буенча урнашкан: Татарстан Республикасы, Зеленодольск муниципаль районы, Карамалы Тау штп Садовая ур. Ж-1 дан (индивидуаль торак йортлар төзү зонасы) Д-1 гә (эшлекле, иҗтимагый һәм коммерция өчен билгеләнгән зона).

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә, шулай ук түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында урнаштырырга: Карамалы Тау штп, Первомайский ур., 70 йорт (җирлекнең административ бинасы), Карамалы Тау штп, Первомайский ур., 30 йорт, «Гадел» кибете янында мәгълүмат стенды; Карамалы Тау штп, Первомайский ур., 13 а йорт, вокзал яны мәйданында мәгълүмат стенды, Карамалы Тау штп, Кузнечная ур., 13 а йорты, «Диана» кибете янында мәгълүмат стенды, Карамалы Тау штп, Кузнечная ур., 16 а йорты, Карамалы Тау штп, «Рубин» кибете янында, Карамалы Тау штп, Б.Кочемировская ур., 2а, «ЮСОН» кибете янында мәгълүмат стенды, Протоповка авылы, Кооператив урамы, 15 нче йорт, ИП Яфизов кибете янында мәгълүмат стенды, Олы Ходяшево авылы, Центральная урамы, 42 нче йорт, Навасардян шәхси эшмәкәр кибетендә мәгълүмат стенды.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Карамалы Тау шәһәр җирлеге башлыгына йөкләргә.

**Җирлек башлыгы,**
**Совет Рәисе:** **Ю. М. Некрасова**